| ИНСПЕКЦИЯ ГОСУДАРСТВЕННОГО СТРОИТЕЛЬНОГО НАДЗОРА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ ТӨЗЕЛЕШ КҮЗӘТЧЕЛЕГЕ ИНСПЕКЦИЯСЕ |
|---|---|---|

ПРИКАЗ БОЕРЫК

_____12.04.2022_____ Казан шәһәре № __54______

Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрен коррупциячел хокук бозуга этәрү максатларында мөрәҗәгать итү фактлары турында эшкә яллаучы вәкиленә хәбәр итү тәртибен раслау турында

«Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы федераль законның 9 статьясындагы 5 өлеше нигезендә

Б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясендә (алга таба – Инспекция) Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрен (алга таба – граждан хезмәткәрләре) коррупциячел хокук бозуга этәрү максатларында мөрәҗәгать итү фактлары турында эшкә яллаучы вәкиленә хәбәр итү тәртибен (кушымтада бирелә) расларга.

2. Инспекциянең структур бүлекчәләре җитәкчеләренә әлеге боерык белән расланган Тәртип белән граждан хезмәткәрләрен имзалатып таныштырырга.

3. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы И.Ф. Сафиуллин

ТР ДТК инспекциясенең 2022 елның
«___» _______ ____ номерлы
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен коррупциячел хокук бозуга этәрү максатларында мөрәҗәгать итү фактлары турында эшкә яллаучы вәкиленә хәбәр итү тәртибе

1. Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрен коррупциячел хокук бозуга этәрү максатларында мөрәҗәгать итү фактлары турында эшкә яллаучы вәкиленә хәбәр итү тәртибе (алга таба – Тәртип) «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы федераль законның 9 статьясының 5 өлеше нигезендә эшләнгән.

Тәртип Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясендә (алга таба – Инспекция) үзләренә карата эшкә яллаучы вәкиле булып Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе җитәкчесе (алга таба – җитәкче) торган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәре тарафыннан аларны коррупциячел хокук бозуга этәрү максатларында мөрәҗәгать итү фактлары турында хәбәр итү процедурасын регламентлый.

2. Тикшерү уздырылган яки уздырыла торган фактлардан тыш, коррупциячел хокук бозуга этәрү максатларында мөрәҗәгать итү фактлары турында хәбәр итү дәүләт хезмәткәрләренең вазыйфаи (хезмәт) бурычы булып тора.

4. Җитәкчегә коррупциячел хокук бозуга этәрү максатларында мөрәҗәгать итү фактлары турында хәбәр итү (алга таба – Белдерү) граждан хезмәткәре тарафыннан Тәртипнең 1 нче кушымтасына ярашлы рәвештә, язмача формада төзелә.

Белдерүдә түбәндәге белешмәләр чагылдырылырга тиеш:

Белдерүдә аны җибәргән затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (атасының исеме булган очракта күрсәтелә), биләгән вазыйфасы һәм структур бүлекчәсе;

Инспекциядә граждан хезмәткәренә, үзенең хезмәт бурычларын үтәвенә бәйле рәвештә, нинди дә булса затларның үзен коррупциячел хокук бозуны кылуга этәрү максатларында мөрәҗәгать итү фактына җирлек туган (очраклар турында мәгълүм булган) хәлләргә (датасы, урыны, вакыты, башка шартлары) тасвирлама;

граждан хезмәткәренә килгән, коррупциячел хокук бозуга этәрү турында таныклаучы мөрәҗәгатькә җентекле тасвирлама (граждан хезмәткәренә карата зат тарафыннан башкарылган гамәлләр, тәкъдимнәр, гаризалар, таләпләр, башкача формадагы мөрәҗәгатьләр), шулай ук граждан хезмәткәре шуны кылу өчен этәрелгән, коррупциячел хокук бозу билгеләре булган гамәлләргә тасвирлама;

коррупцион хокук бозу кылуга этәрүче физик (юридик) зат турында барлык мәгълүматлар;

коррупциячел хокук бозуга этәрү ысулы һәм шартлары (сатып алу, янау,

алдау, шантаж һ.б.), шулай ук затның коррупциячел хокук бозу турындагы тәкъдименнән баш тартуы (аны кабул итүе) турында мәгълүмат;

Белдерүне прокуратура органнарына яки башка дәүләт органнарына (нинди) җибәрү датасы.

Белдерүгә нинди дә булса затларның граждан хезмәткәрен коррупциячел хокук бозуга этәрү максатларында мөрәҗәгать итү хәлләрен раслаучы булган барлык материаллар кушып куела.

Белдерү Инспекция җитәкчесе (аның вазыйфаларын башкаручы зат) исеменә языла һәм коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи затка (алга таба – Җаваплы зат) кичекмәстән тапшырыла, әгәр әлеге тәкъдим эш вакыты булмаган чорда алынган икән, – эш урынына килеп җитү белән, кичекмәстән тапшырыла.

Граждан хезмәткәре вазыйфаи (хезмәттәге) бурычларын үтәмәгән урында яки даими хезмәт итү урыныннан читтә булганда Белдерү почта аша юллап, алга таба Белдерүнең төп нөсхәсен хезмәткә кайту белән Җаваплы затка тапшыру юлы белән, факсимиль элемтә каналлары яки мөмкин булган бүтән электрон элемтә каналлары аша җибәрелергә мөмкин.

5. Җаваплы зат әлеге Тәртипкә 2 нче кушымта формасында Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен коррупциячел хокук бозуларны кылуга этәрү максатларында мөрәҗәгать итү фактлары турында белдерүләрне теркәү журналында (алга таба – Журнал) Белдерүне терки.

6. Белдерү Журналда теркәлгәннән соң дәүләт хезмәткәренә Белдерүне алган зат турында белешмәләрне һәм аны теркәүгә алу датасын күрсәтеп, Белдерүнең күчермәсе кул куйдыртып тапшырыла. Гариза почта аша килгән очракта, Белдерүнең күчермәсе Белдерүне җибәргән граждан хезмәткәренә почта аша заказлы хат белән җибәрелә.

Белдерүне теркәүдән баш тарту, шулай ук Белдерү күчермәсен тапшырмау – рөхсәт ителми.

Алынган белешмәләрнең конфиденциальлеге «Персональ белешмәләр турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы федераль закон таләпләренә туры китереп тәэмин ителә.

7. Җаваплы зат Белдерүне теркәгән көнне аны, эчке эшләр органнарына яки башка дәүләт органнарына җибәрү турында карар кабул итү өчен, Инспекция җитәкчесенә (аның вазыйфаларын башкаручы затка) карау өчен тапшыра.

8. Инспекция җитәкчесе (аның вазыйфаларын башкаручы зат) Белдерүне эчке эшләр органнарына яисә башка дәүләт органнарына җибәрү турында карар кабул иткән очракта, Җаваплы зат, әлеге карар кабул ителгәннән соң ике эш көненнән дә соңга калмыйча, теркәлгән материаллар белән Белдерүне җибәрә.

9. Җаваплы зат мондый карар кабул ителгәннән соң 10 эш көненнән дә артмаган срокта Белдерүне җибәргән граждан хезмәткәренә кабул ителгән карар турында хәбәр итә.

10. Эшкә яллаучы вәкиленә, прокуратура органнарына яки башка дәүләт органнарына үзен коррупциячел хокук бозуларны кылуга этәрү максатларында мөрәҗәгать итү фактлары турында хәбәр иткән граждан хезмәткәре Россия

Федерациясе законнары нигезендә дәүләт яклавында тора.

11. »Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы федераль законның 9 статьясы нигезендә, Инспекциянең дәүләт хезмәткәре тарафыннан коррупциячел хокук бозуларга этәрү фактлары турында эшкә яллаучы вәкиленә хәбәр итү бурычын үтәмәү аны дәүләт хезмәтеннән кууга яисә Россия Федерациясе законнары нигезендә аны башка төрле җаваплылыкка тартуга китерә торган хокук бозу булып тора.

ТР ДТК инспекциясенең ___________ №_____ боерыгы белән расланган Тәртипкә 1 нче кушымта

ТР ДТК инспекциясе җитәкчесенә
___________________________________
(Яллаучы вәкиленең Ф.И.А.*)
___________________________________
(Хезмәткәрнең Ф.И.А.*, вазыйфасы һәм
___________________________________
структура бүлекчәсе, яшәгән
___________________________________
урын адресы,телефон номеры)

Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрен коррупциячел хокук бозуга этәрү максатларында мөрәҗәгать итү фактлары турында эшкә яллаучы вәкиленә
БЕЛДЕРҮ

1. Мине коррупциячел хокук бозуга этәрү максатларында мөрәҗәгать итү факты турында (алга таба – хокук бозуга этәрү) турында хәбәр итәм, ________________________________________________________________
(хокук бозуга этәрә торган затның Ф.И.А.*, вазыйфасы, физик (юридик) зат турында мәгълүм булган барлык белешмәләр)
________________________________________________________________

2. Хокук бозуга этәрү минем тарафтан түбәндәгеләрне гамәлгә ашыру максатларында
башкарылды________________________________________________________
________________________________________________________________
(күздә тотылган хокук бозуның асылы күрсәтелә)

3. Хокук бозуга этәрү түбәндәгечә гамәлгә ашырылды_______________
________________________________________________________________
(этәрү ысулы: сатып алу, янау, алдау һ.б.)

4. Хокук бозуга этәрү ____сәг. _____минутта булды,
20___ елның «____» _____________.
____________________________________________________________
(шәһәр, адрес)

5. Хокук бозуга этәрү түбәндәгечә башкарылды_________________________
________________________________________________________________
(этәрү шартлары: телефон аша сөйләшү, шәхси очрашу, почта һ.б.)

6. Шулай ук белдерү турында да хәбәр итәм

______________________________________________________________________________

(прокуратура органнарына яки башка дәүләт органнарына (кайсы) хәбәр итү датасы)

____________________________________________________________________________.

| | | |
|---|---|---|
| ________________ | ________________ | _______________________________ |
| (дата) | (имза) | (тулы имза) |

* - *ата исеме булган ата булган очракта күрсәтелә*

ТР ДТК инспекциясенең ___________ №_____ боерыгы белән расланган Тәртипкә 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясендә
Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрен коррупциячел хокук бозуга этәрү максатларында мөрәҗәгать итү фактлары турында эшкә яллаучы вәкиленә белдерүләрне теркәү
ЖУРНАЛЫ

| т/с | Бел-де-рүне тер-кәү да-тасы | Белдерүне тапшырган затның Ф.И.А.*, вазыйфасы | Хәбәрне тапшырган затның имзасы | Теркәү-ченең Ф.И.А.* | Теркәүче-нең имзасы |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |

* - *ата исеме булган ата булган очракта күрсәтелә*